ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

02.04.2024 с. Татарское Бурнашево 01

«Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылында 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставы белән, 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (2023 елның 29 ноябрендәге 1532 номерлы редакциядә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән

КАРАР БИРӘМ:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылына гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыенына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 12 апреленә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Каинки авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:
торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту
(Каинки авылында юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм товарны тәэмин итүче хисабына билгеләнгән пунктка кадәр китереп җиткерү).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Каинки авылы, Үзәк урамы, 18 йорт адресы буенча 10.30 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин